*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№4 (31)

Апрель, 2019 нчы ел

Бу санда:

| | |
|---|---|
| *Гимназия сулышы* | *1* |
| *#Экояз—2019* | *2* |
| *#Спорт көндәлеге* | *2* |
| *“Китап корты” муниципаль проекты* | *3* |
| *Фоат Садриев укулары - 2019* | *4* |
| *“БЕЗ БЕРГӘ” халык иҗаты республика фестивале* | *4* |
| *Иҗади сәхифә* | *4* |

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### СЕРЛЕ КАЛӘМ - 2019



Факил Сафин исемендәге Мөслим муниципаль районы мәктәп балалары һәм яшьләр арасында узган “СЕРЛЕ КАЛӘМ - 2019” иҗат конкурсы “ЖУРНАЛИСТИКА” номинациясе буенча Рәхмәтуллина Әдилә – 1 нче, Нассер Мәрьям – 2 нче, Ханнанова Алина, Сабитова Айгөл, Солтанова Алия 3 нче урын яуладылар. “ПОЭЗИЯ” номинациясе буенча Солтанова Алия, Шәмсиева Камилла 3 нче урынга лаек булдылар. Өлеге конкурста мәктәп газеталары арасында Мөслим гимназиясенең “ТЫЛСЫМ+” газетасы 1 урын яулады. Укучыларны Г.М.Солтанова, Э.В.Тимергалиева, З.З.Авзалова, Г.М.Мирзамуратова әзерләде.

### “Тере классика”

Гимназия базасында район күләмендә “Тере классика” (“Живая классика”) әдәби конкурсы узды. 8 нче а сыйныфы укучысы Борһанова Рената, 6 нчы а сыйныфы укучысы Бәдретдинова Әдилә 1 нче урын, 7 нче а сыйныфы укучысы Кәримова Ләйлә 2 нче урын, 5 нче а сыйныф укучысы Сәхипгәрәева Ализә 3 урын яулады.

Укытучылары: Хәйруллина Ч.А., Фазлыева А.В., Галиева И.Т.





### Математик мәсьәләләр конкурсы

Туган якка бәйле эчтәлекле математик мәсьәләләр район конкурсында 8 нче а сыйныфы укучысы Хәбибуллина Камилә - 1 нче, 6 нчы а сыйныфы укучысы Бәдертдинова Әдилә - 2 нче, 5 нче а сыйныфы укучысы Рәхимуллина Аделина, 5 нче б сыйныфы укучысы Вяткин Владислав, 4 нче а сыйныфы укучысы Хатипова Ралинә - 3 нче урын яуладылар.

Фәнни җитәкчеләре: Р.С.Госсамова, Г.Ә.Асылгәрәева, Мортазина Л.Г., А.Р.Кадыйрова.




### Агитбригада конкурсы

Гимназия базасында Мөслим муниципаль районында балалар арасында юл-транспорт травматизмын кисәтү юнәлешендә “Кызыл, сары, яшел” дип аталган агитбригадалар конкурсында гимназия командасына тиңнәр булмады. Беренче урын яулаган 3 нче а сыйныфын һәм җитәкчесе А.Р.Гомәрованы зур җиңүләре белән котлыйбыз!

## #ЭКОЯЗ—2019 #ГИМНАЗИЯ

**Апрель аенда республикада “Экояз - 2019” (“Эковесна - 2019”) айлыгы старт алды. Бу айлыкның һәр көне мавыктыргыч чаралар, җәмгыятькә файдалы хезмәт, танып белүне үстерүгә юнәлдерелгән проектлар белән истә калыр.**

“Яшел Мөслим” акциясенә кушылып, территория җыештыру өмәләре гөрләп үтте. Барлык укучылар, укытучылар, техник хезмәткәрләр актив катнашты.

Гимназия күләмендә макулатура җыю уйнкөнлеге игълан ителде һәм барлыгы 4 тоннага якын иске кәгазь җыелды. Ә сез барыгыз да беләсезме? Җиңүче сыйныфларның принтер һәм шәхси беренчелектә җиңүчеләрнең шәхси бүләк алырга мөмкинлеге бар.



“Һәр сыерчык өчен – яңа оя!” конкурсында 1-7 нче сыйныф укучылары катнашты. Бигрәк тә башлангыч сыйныф укучылары актив булуын билгеләп үтәргә кирәк. Әти-әниләр ярдәме белән, 50 гә якын оя ясадык. Барлык оялар гимназия территориясендә һәм парктагы агачларга урнаштырылды.





Озынайтылган көн төркемендә тәрбияләнүчеләр өчен “Кошлар көне” бәйрәме, 2 нче а, 7 нче а, 7 нче б сыйныфларында узган “Үз уеным” интеллектуаль-мәгълүмати уены укучыларның белемле булуын күрсәтте (И.В.Латыйпова, Л.Ф.Бариева).



Чүплеккә ташларга әзерләнгән пластик савытлардан искитмәле матур, файдалы предметлар ясарга мөмкин икән, ләбаса! 3а сыйныфы укучылары (А.Р.Гомәрова) кул астындагы материаллардан гөл савытлары ясадылар. Төрле төсләргә буяп ясаган савытлар күз явын алырлык матур булып чыкты.





Дүртенче сыйныф укучылары “Табигатьне саклагыз” темасына проект ясадылар. Эшләр тирән мәгънәле, эчтәлекле. Укучылар үзләрен төрле өлкәләрдә белгечләр итеп сынап карадылар. Игътибарга лаек дип табылган проектлар алга таба тормышка ашырылыр дип өметләнәбез (А.Р.Рәхмәтуллина, Л.Г.Мортазина, Л.Ә.Фәхретдинова).

5 нче сыйныфлар арасында экологик темага лэпбуклар конкурсы узды, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды. Укучыларның фантазиясе, фикер киңлеге барыбызны да шаккаттырды. Булдырасыз, “бишенчеләр”!



Яз көне организм талчыга, витаминнарга мохтаҗ була. 6 нчы а сыйныфы укучылары яз көне дөрес туклану турында тәрбия сәгате уздырдылар һәм витаминлы коктейль, смузи ясау буенча мастер-класста катнаштылар. Яшел, кызыл, сары смузилар – витамин чыганагы. Организмдагы витамин кытлыгын җиңәргә булыша торган коктейльләрне без дә татып карадык. Без - сәламәт яшәү, дөрес туклану яклы. Сез дә кушылыгыз!

## #СПОРТ КӨНДӘЛЕГЕ #ГИМНАЗИЯ



**Билбау көрәше.** Татарстан Республикасы укучыларының XII Спартакиадасы кысаларында Чирмешәндә узган билбау көрәше буенча республика беренчелегендә 2004-2005 нче елгы яшүсмерләр арасында ярышларда 10 нчы б сыйныфы укучысы Әхмәтҗанов Данис 2 нче урын яулады. Укытучысы: Сәетгалиев И.Н.

**Армрестлинг.** Түбән Кама шәһәре беренчелегенә узган армрестлинг ярышларында Ногуманов Аяз, Ситдиков Алмаз – 3 нче, Сөләйманов Ранис – 2 нче, Гайнуллин Ислам һәм Бариев Илһам – 1 нче урын яуладылар.



# ГАМЬЛЕ УКУ

***"Үзенең туган ягын, үзе белән бергә яшәгән якташларын әдәби биеклеккә күтәргән, ихлас зурлаган, кадерләп тасвир кылган башка язучы бармы бүген әдәбиятыбызда? Юктыр. Гомер буе үзе туып үскән якка – Мөслим төбәгенә тугры булып кала алган һәм туган ягында олуг Әдип, Шәхес булып җитешкән Ф.Садриев булып туарга, яшәргә, иҗат итәргә кирәктер"***

***Факил Сафин***

***"Китап корты" район проекты кысаларында гимназиядә Фоат Садриев хикәяләрен уку барышында туган як табигате сурәтләренә игътибар итеп уку дәресләре узды. Укучыларның табышлары белән танышып үтегез.***

Авыл! Минем күпчелек уйларым, иң кайнар, иң кадерле кичерешләрем синең белән бәйле. Чөнки син безнең, сугыш еллары балаларының, икенче әти-әнисе булдың. Салам түбәле кечкенә өйдә бозау, бәрәннәр белән бергә җылынып та, вакыт-вакыт туңып та, сукыр лампа яктысында укып-язып та үсмерлеккә үрмәләдек. Сөякләребездән тирләр чыкканчы утау утаулар, чөгендер эшкәртүләр, печән чабулар, карлы яңгыр асларында чөгендер йолкулар, озын кыш буе ат белән фермаларга салам ташулар – барысы да булды. Ә шулай да, күпме генә авырлыклар күрсәк тә, мин, авылым, сине яратам, ул авырлыклар өчен сине аз гына да гаепләмим. Чөнки яшәргә кирәк, ашлыгын да, итен-сөтен дә, башкасын да җитештерергә кирәк иде. Шуңа күрә вакыты белән тузә алмаслык чакларда да түздек. Бик авыр яшәсәк тә, син мине саклап калдын, үстердең, чыныктырдың һәм тәрбияләдең. Минем җанымның йөздән туксан тугыз өлеше синең туфрагыңнан һәм синең рухыңнан ясалган, безне синең белән уртак кан әйләнеше бәйли. Шуңа күрә дә сиңа кагылышлы һәрнәрсә минем җаныма килеп тия. Сиңа түлисе бурычларым бихисап күп минем. Сине бик тә, бик тә яшәтәсем килә. Инде заманалар үзгәргәч, кычыткан, кәлҗемә ашаулардан, читән, чабата, сукыр лампалардан котылгач, ат сабаннарына, кул ураклары алмашка куәтле техника килгәч, синең бик тә бәхетле итеп яшәвеңне күрәсем килә.

*"Яшәтәсе иде сине..."*
*мәкаләсеннән*

Аларны суы көмештәй җемелдәгән Ык каршы алды. Дәррәү кубып, малайлар суга ташланды...

*"Алып тавы" хикәясеннән*

Җир өстендә тәгәрәп йөри торган кояш булса, ничек рәхәт яшәр идек.

*"Көнбагыш чәчәге"*
*хикәясеннән*

Әнә тау артыннан, бик зур түбәтәй төсле булып, кояшның түбәсе күренде.

*"Арышлар сөйләшкәндә"*
*хикәясеннән*

Өй кыегындагы боз сөңгеләрен елата башлаган кояшлы көн иде.

*"Тургай нәрсә дип җырлый?"*
*хикәясеннән*

Күктә – мамык өемнәре төсле кабарынкы ак болыт төркемнәре һәм кайнар кояш....

*"Алып тавы"*
*хикәясеннән*

Алтын чүмеч белән су салып йөгерткәч, ай балкып китте...Әни һавадагы йолдызларны алсу пыяла табакка чүпли. Табак йолдызлар белән тулды, һәрберсе җем-җем итеп, ялык-йолык килеп тора.

*"Арышлар сөйләшкәндә"*
*хикәясеннән*

Син туган җирендә яши алуын белән нинди бәхетле! Шатлан, рәхәтләнеп уйна-көл, якты тормышка, шушы җирдә яшәвеңә рәхмәт укы! Шушы дөньяны, кояшны, зәңгәр күкне, алтын иген басуларын саклаучыларга һәм ямьләндерүчеләргә хөрмәт белән баш и!

*"Тургай нәрсә дип җырлый?"*
*хикәясеннән*

Кояш алтын бишегендә яткан килеш уянып күзен ачуга, җиһанга алсу нур иңә. Таң белена, таң ата... Таң, таң, таң... Исеме үк чынлап, моң таратып, җырлап тора. Чаң каккан шикелле. Ул арада, алтын бишегенең зәңгәр пәрдәсен куллары белән аралап, кояш киерелә-киерелә күтәрелә, елмаеп җибәрә. Җиһанның түнгелеккә сүрелгән, йокыга чумган тормыш елгасы кабат ташый башлый...

*"Таң җиле" романыннан*

Көн буе эссе җил тараган агач яфраклары, үлән сабаклары татлы изрәү эчендә тын калганнар. Аларның меңнәрчә сизгер тамырлары Ык суының яр туфрагына сеңгән дымын татканып суыралар, әлсерәп сусаган яфракларга, сабакларга әче сүл китерәләр. Алар саллылана, тирләгәндәй ялтырый башлыйлар, күзәнәкләре бүртенүдән булса кирәк, һавага тере үсемлек эченнән әле яңа гына сыгылып чыккан салкынча хуш исләр җәелә...

*"Таң җиле" романыннан*



**Фоат Садриев**

Автор шулай ук йорт хайваннарын тасвирларга бик ярата. Әлбәттә, бу аңлашыла да. Авыл кешесе малтуарсыз яшәми. Авылның бөтен яме шуларда. Шуңа күрә ул хайваннарның, кош-кортларның кичерешләрен, психологиясен сурәтләгәндә дә адәми затның күңеленә тиярлек итеп яза: көмеш кыңгыраулар тавышы белән сабан тургае сайрый, куе булып үскән таллар уртасында, тәбәнәк кенә комсу калкулык булып үгез ята... Каз каңгылдаганы ишетелә, аксап кына йөри торган, иптәшләреннән гел читтә калган мескен бәбкә кызганыч тавыш белән "пип-пип" дип кычкыра....Инештә бармактан әз генә зуррак, сыртлары тал яфрагы төсле озынча балыклар йөзеп йөри... Болар барысы да Ф.Садриевның үзенә генә хас тасвирлаулар. Ул гына, вакыйгаларны күңеленең түреннән алып, юмор белән сугарылган шундый әсәрләр тудыра ала.

***"Тормыштан алынган әдәбият кына озын гомерле була, аны халык ярата, үзенеке итә, чөнки анда үзен таба, үзен тапмаса да, яшәү өчен сабак ала. ...Еллар үтәр, вакыт үткән саен мондый тормыштан алып язылган әсәрләребезнең рухи бәһасе арта төшәр".***

***Гурий Тавлин***

Тургайлар сайравы, үгез холкы, каз каңгылдаганы, арышның серкәгә утыруы, яфрак лепердәве, сабан бәйрәме турында язсынмы, кешенең олы дөньядагы урыны турында уйласынмы - һәммәсе артында язучының үзенең шәхси кабул итүен күрәсең, нечкә күңелен сизәсең. Үзәктә кеше җаны. Ф.Садриев аның һәр борылышына игътибарлы. Мең еллык тирән тамырлы имән агачы кебек, бу иҗат халкының бәгыренә, күңеленә барып тоташкан, ул аннан көч, дәрт, дәрман алып, һәр яңа буынга, түкмичәчми җиткерергә тырыша.

# ГИМНАЗИЯ – ТАЛАНТЛЫ БАЛАЛАР ТЕРРИТОРИЯСЕ

## “БЕЗ БЕРГӘ” халык иҗаты республика фестивале

Узган ай дәвамында район мәктәпләрендә “Без бергә” халык иҗаты республика балалар сәнгать фестивале узды. Муниципаль этапта җиңү яулап, 6 нчы а сыйныфыннан Идиятуллиннар һәм 2 нче б сыйныфыннан Фәрхетдиновлар гаиләсе 1 нче, Искәндәровлар гаиләсе (6а) 3 нче дәрәҗә Дипломга лаек булды. Шәхси чыгышлар буенча Әмир Гамиров (5б) – 1 нче, Әдилә Бәдертдинова (6а), Лилиана Нургалиева (3а) - 2 нче дәрәҗә дипломга ия булдылар. “Беләзек” фольклор ансамбле, “Калфак” кызлар ансамбльләре 1 дәрәҗә Диплом белән бүләкләнде.



Гимназиянең “Калфак” ансамбле Актанышта узган “Без бергә” халык иҗаты республика балалар сәнгать фестиваленең йомгаклау турында нәтиҗәле чыгыш ясады. Жюри әгъзаларының ихтирамын яулаган ансамбль кызлары укуда да сынатмый. Киләчәктә гимназиянең “йөзек кашы” булырлар дигән өметтә калабыз.

Ансамбльнең уңышы - укытучының да, балаларның да зур хезмәте нәтиҗәсе. Сәнгать җитәкчесе - талантлы музыкант, тынгысыз шәхес Гөлнур Әзһәм кызы Фәхертдинова укучыларыбызга сәнгать тәрбиясе, сәхнә культурасы, музыкаль тәрбия бирүдә армый-талмый эшли. Балаларга сәхнә киемнәре тектерүдә спонсорлык ярдәме күрсәткән гимназия директоры А.Ф.Мирзаяновка һәм ата-аналар коллективына газета аша рәхмәтләребезне җиткерәбез.

## “ЯШЬ БӨРЕЛӘР” конкурсы



Һәр ел саен уздырылып килүче “Яшь бөреләр” район конкурсында да гимназиянең “Калфак” ансамбле 1 нче дәрәҗә, вокаль трио 2 нче дәрәҗә, Сәгдиева А. - 3 нче дәрәҗә дипломнарга лаек булдылар. Борһанова К. “Өмет” номинациясе җиңүчесе дип табылды. Укучыларны конкурска әзерләүче педагог - музыка һәм сәнгать укытучысы Фәхертдинова Г.Ә.

## ФОАТ САДРИЕВ УКУЛАРЫ - 2019



*“Фоат Садриев укулары” 6 нчы мәртәбә уздырыла. Быелгы укулар - Бөтенрәсәй күләмендә уздырылучы чара буларак тарихка кереп калачак. Беренче укуларда 37 укучы катнашса, соңгы елларда “Фоат Садриев укулары”ның дәрәҗәсе дә арта, географиясе дә киңәя, катнашучылар саны да 100 гә җитте. Барлык катнашучыларга уңышлар юлдаш булсын!*

# ИҖАДИ СӘХИФӘ

## КЫСКА ШИГЫРЬЛӘРДӘ – ФӘЛСӘФИ ЭЧТӘЛЕК ҺӘМ ЛИРИК НӘФИСЛЕК

**Берьюллыклар**

Тел – йозак.
*Аяз Ногманов*

Дуслык – алтын.
*Лиана Хәбибуллина*

Бала – моң.
*Диләрә Зыязова*

**Икеюллыклар**

Мәктәп – вакыт,
Яшәү – китап.
*Шамил Баянов*

Әни –канат,
Әти – туфрак.
*Лиана Хәбибуллина,*
*Фәнисә Әхмәдиева*

Гомер – мизгел,
Кабер –хәтер.
*Алмаз Ишматов*

Сүз – ачкыч,
Вакыт – баскыч.
*Лиана Хәбибуллина*

ТЫЛСЫМ+
Апрель, 2019 нчы ел
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Ханнанова Алина
**Корректорлар:** Сабитова Айгөл, Әхмәтҗанов Булат
**Корреспондентлар:** Бәдертдинова Әдилә, Нассер Мәрьям
**Дизайнер:** Харитонов Динар

**Компьютерда җыючылар:** Хафизова Луиза, Абдуллина Миләүшә
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru